**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

дүртенче утырыш

# КАРАРЫ

10 декабрь 2025 ел **№ 17** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2025 елның 31 гыйнварындагы 303 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Советының 2025 елның 31 гыйнварындагы 303 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

- күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында нигезләмәгә:

А) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кадастр бәясе нигезендә аренда түләве күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$\mathbf{А_П = К_С \times К_Ф},$$

монда:

$\mathbf{А_П}$ - аренда түләвенең еллык суммасы;

$\mathbf{К_С}$ - күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры мәгълүматларына нигезләнеп билгеләнә торган җир кишәрлегенең кадастр бәясе;

$\mathbf{К_Ф}$ - җир категорияләре һәм җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре буенча билгеләнә торган коэффициент.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Теләче муниципаль районы Башлыгы А.Г. Фәтхуллин